Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының бишенче чакырылышының сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

21 май, 2026 ел № 59

Питрәч авылы

2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру йомгаклары һәм 2036 елга кадәр чорга Стратегияне гамәлгә ашыру бурычлары турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру йомгаклары һәм 2036 елга кадәр чорга Стратегияне гамәлгә ашыру бурычлары турында мәгълүматны тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Питрәч муниципаль районы милкенең барлык рәвешләрендәге учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә Россия Федерациясе милли сәясәте Стратегиясендә каралган чараларны гамәлгә ашыруны югары дәрәҗәдә дәвам итәргә тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетына чаралар үткәрүгә даими мониторинг һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә, шулай ук рәсми булмаган иҗтимагый оешмаларда һәм берләшмәләрдә балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең радикальләшүен булдырмауга юнәлдерелгән;

- Россия Федерациясе халыклары тарихында әһәмиятле бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган;
- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе күпмилләтле халкының рухи, тарихи һәм мәдәни мирасын саклап калу һәм үстерү буенча, патриотизм, халыклар бердәмлеге һәм дуслыгы, шулай ук милләтара (этникара) татулык идеяләрен популярлаштыру аша;
- милли спорт төрләрен үстерү буенча;
- этнографик һәм мәдәни-танып белү туризмын үстерү буенча.

4. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Питрәч районы бүлеге белән берлектә чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның легаль булмаган яшәве һәм законсыз хезмәт эшчәнлеге фактларын кисәтү, ачыклау һәм булдырмау эшен дәвам итәргә;

- билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән торак урыннарында чит ил гражданнарын теркәү очракларын ачыклау өчен миграция хезмәтенең территориаль органы белән даими рәвештә чагыштырулар үткәрергә һәм ачыкланган фактлар ачыкланган саен район прокуратурасына хәбәр итәргә;

- районның рухи лидерлары белән даими элемтәдә торырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов